Рузил Фазлыев

# *Егерменче ел*

Шигырь вәгазь. Том 3. Стихи

**Рузил Фазлыев**

# Егерменче ел. Шигырь вәгазь. Том 3. Стихи

*http://www.litres.ru/pages/biblio_book/?art=68070416*
*ISBN 9785005900067*

## Аннотация

Бу китап алдагы ике китапның дәвамы. Егерменче елда язылган шигырләр тупланган. Шигырләрнең күпчелеге вәгазь стилендә язылган. Бизәү, матурлау кулланылмаган, иң гади форматта эшләнгән. Бу электрон китапны үзләштерүгә ясалган беренче адымнар. Иң беренче максат, булган бар шигырләрне барлап, саклап калу максатында ясарга тырышу булып кала. Караучылар, укучылар фикерен ишетүгә бик шат булыр идем.

# Содержание


| | |
|---|---|
| Ялгыз җыр | 8 |
| Соңгы бүләгем | 10 |
| Килә язмыштан | 12 |
| Фикер килә | 13 |
| Кеше хакы | 15 |
| Күңел җыры | 17 |
| Сабантуй чоры | 19 |
| Бертуганнар | 21 |
| Гомер тавы | 23 |
| Сыналу вакыты… | 24 |
| Онытма язларны | 26 |
| Килде вакыт | 27 |
| Бер хуҗа | 29 |
| Җәй | 31 |
| Озату | 33 |
| Сәясәт | 35 |
| АллаХ сүзе | 37 |
| Июнь | 39 |
| Сәләм бирик | 41 |
| Язмышка | 43 |
| Яңа тормыш | 45 |
| Урамда аккош | 47 |
| Сулар ага | 49 |

Туган тел 51
Җирдәгеләр 53
Хобби 55
Бәйрәмме 57
Ниләр истә 59
Ифтар 61
Үзгәреш 63
Бүген 65
Ике күпер 67
Конец ознакомительного фрагмента. 69

# Егерменче ел Шигырь вәгазь. Том 3. Стихи

# Рузил Фазлыев

© Рузил Фазлыев, 2022

ISBN 978-5-0059-0006-7 (т. 3)
ISBN 978-5-0056-9347-1
Создано в интеллектуальной издательской системе Ridero

сравнить

# Егерменче ел



Бу китап алдагы ике китапның дәвамы. Егерменче елда язылган шигырьләр тупланган. Шигырьләрнең күпчелеге вәгазь стилендә язылган. Бизәү, матурлау кулланылмаган, иң гади форматта эшләнгән. Бу электрон китапны үзләштерүгә ясалган беренче адымнар.

Иң беренче максат, булган бар шигырьләрне барлап, саклап калу максатында ясарга тырышу булып кала. Караучылар, укучылар фикерен ишетүгә бик шат булыр идем.

Рузил Фазлыев

# Ялгыз җыр

Сәхнә уртасында ялгыз җырчы,
Матур итеп җырлар җырлады.
Тын алырга куркып тыңлаучысы,
Тыңлады да, аны тыңлады…

Җыры саен моңы арта кебек,
Күңеленнән чыккан җылы бу.
Хәтирәләр ташкыннары кебек,
Сагыш дигән язмыш җыры бу.

Башланада чишмә агышыдай
Ул әйләнә көчле агымга.
Халык күңеле саегалмас әле,
Шундый җырчылары барынды.

Җырчы җыры, олы кораб кебек,
Ерак диңгезләрдә йөзгәндәй.
Аның белән күңел җырлагандай,
Аның сагышларын сизгәндәй.

Җырчы шулай җырын бүләк итә,
Яшәү өчен биреп өметләр…
Күбрәк булсын иде әле җирдә,
Шушы ялгыз җырчы кебекләр.

# Соңгы бүләгем

Сагынулар, түгел офтанулар,
Хәтерләрдә кайту үткәнгә.
Үткән юллар барсы үземнеке,
Ул юлларны хөрмәт иткәнгә.

Әйтәм икән булган фикерләрне,
Кысмасыннар алар йөрәкне.
Булганыңны кеше белән бүлеш,
Ул кемгәдер булыр кирәкле.

Хыял сызмыйм, нидер төзү өчен,
Андый куәттә юк беләктә.
Әйтеп калам әле онытканчы,
Саклап калганнарны йөрәктә.

Җирдә яшәү үзе олы бәхет,
Шуны аңлап яшәү кирәген.
Туймас кебек яшәп китәбездә,
Аңламыйча Аллаһ биргәнен.

Көнделдәне әйтеп бара алсам,
Тынычлана алыр йөрәгем.
Шөкерләрем, бөтен рәхмәтләрем,
Шигырь булып, соңгы бүләгем.

# Килә язмыштан

Кеше язмышы ул кешенеке,
Кирәк түгел аңа көнләшү.
Мөмкин мени, кеше көче белән,
Язмыш белән язмыш берләшү.

Кабатланмый язмыш сукмаклары,
Янәшә һәм бергә узсада.
Бер мизгельдә төгәл кабатланмый,
Бер карашка охшаш булсада.

Кабатланмас яшерелгән серләр,
Башка беркем белә алмаслык.
Кай вакытта авыртулы була,
Башка кеше түзә алмаслык…

Кыйммәтедә җирдә кешеләрнең,
Бердәм булып бергә булуда.
Вакланмыйча, кирәк булмаганга,
Дөрес итеп тормыш коруда.

Кеше булып кала белә алу,
Җирдә яшәүләрнең бүләге.
Хөрмәт белән карау язмышларга,
Яшәү өчен иң-иң кирәге…

# Фикер килә

Кирәкмидер үпкә саклап яшәү,
Аңламый дип сине кешеләр.
Үз үзеңне кайчак аңлап булмый,
Көтмик шуңа башка кешедән.

Син күргәнне, башка яратмаса,
Кеше уе сиңа охшамас…
Булган шикләреңнән арынмасаң,
Күңелләрең һичтә бушамас.

Кеше күңеле аерым дөнья кебек,
Кануннары була төрлечә.
Кеше күңелләре күренми шул,
Бәя биреп булмый күрмичә.

Уйланасың, шикләнәсең кайчак,
Ышанулар җиңә күберәк.
Ялгышулар юлдаш була икән,
Авыр чагы, шунда бигерәк.

Дөрес фикер килә еллар үткәч,
Кирәк кебек бәлки булмаста…
Ничек дөрес, ничек булган диеп,

Чагыштырып карап тормаска.

# Кеше хакы

Ана хакы, бала хакы дибез,
Бу сүзләрне кемнәр белмидер.
Күңеленә сала алмаганнар,
Күпме михнәт җирдә күрмидер.

Хак дигәне, безнең бурычлар,
Без кыласы булган гамәлләр.
Бала өчен дөрес юл күрсәтү,
Ана өчен дога – сәләмнәр.

Хак дигәндә, дөрес чамалап,
Күпме алдың, күпме бирәсең.
Әзер булып, бүгенгеләр өчен,
Иртәгәсенниләр күрәсен.

> Тиеш гамәл соңармаска тиеш,
> Вакытлары барсы билгеле.
> Булганнары бары синекеме,
> Әллә аны Ходай бирдеме…

Минеке дип әйтү дөрес микән,
Кылган гамәлләрдән башкасын.
Кеше хакы, кеше өлеше ул,

Күңелләрдә генә ятмасын.

Ала белгәч, бирә белү кирәк,
Калган эшкә «карлар яумасын».
Кеше хакы, Ана-бала хакы,
Үтәлмичә җирдә калмасын…

# Күңел җыры

Ишеттемдә шушы моңлы җырны,
Онытылып әллә кителде…
Гомер буе шушы җырны эзләп,
Бүген генә таптым шикелле.

Үткәннәрнең әллә сәләмеме,
Әллә килеп хәзер иреште.
Күңел алданамы әллә шулай,
Диңгез диеп, аккан инешне.

Җыр агыла җанга сихәт биреп,
Тыңлаганда уйлар уйладым.
Таң калып мин бары тыңлый алдым,
Юраргада хәттә кыймадым.

Күңел җыры булып ишетелде,
Көтеп алган бәйрәм шикелле.
Күңел өчен олы сихәт булды,
Күптән аны көткән бит инде.

Бу моң әллә озак сакланганмы,
Бик тирәндә йөрәк түрендә…
Ишетелер өчен, күңел җыры,
Олы бүләк булып бүгенгә…

# Сабантуй чоры

Тальян гармун моңнар таратыр,
Сабантуйлар чоры җиттеләр…
Сабантуйдан сабантуйга кәдәр,
Тагын көннәр үтеп киттеләр.

Еллар үтә сабантуйлар көтеп,
Бәйрәм көтеп, көтеп күрешү.
Сәләмләшеп, бергә җыелып,
Бер береңнең хәлен белешү.

Җыен иде, аның исемнәре,
Без үскәндә, йөгереп урамда.
Шулай бергә халык җыела ала,
Авылларда җыен булганда.

Кичектереп бераз кайтуларны,
Көтеп тора җыен чорларын.
Күз алдында тота өмет белән,
Ишетәсен тальян моңнарын.

Быел тагы шулай көтәбездә,
Булыр микән диеп җыеннар.
Сабантуйлар булмый кала алмый,
Халык яши, халык җыелган!

# Бертуганнар

Бер анадан туган, малай, кызлар,
Газиз балалары ананың.
Бертуганнар яши алган өчен,
Зур хөрмәткә хакы бар аның.

Апамы ул, абый, энеме,
Сеңлесеме – барысы туганнар.
Җан җылысы барсы бер кешенең,
Бер карында алар булганнар.

Җан иңдергән ходай бер урында,
Бер үк булган ана җылысы.
Ана өчен барысы тигез була,
Кечкенәсе, урта, зурысы…

Кабатланган бишек җырларыда,
Берсе артыннан берсе үскәннәр.
Бер өстәлдә утырып тезелешеп,
Җыелышып чәйләр эчкәннәр.

Иң зур бәхет шуны тоеп яшәү,
Тормышыңда булу туганың.
Истә тотып туган булуларны,

Хәлләреңне белә торганың.

# Гомер тавы

Юллар, юллар һаман чакыралар,
Ул юлладан ничек туясың.
Озын микән үткән юллар диеп,
Кайвакытта уйлап куясың…

Артта калды, үргә менгән чаклар,
Югарыда күреп өметләр.
Агай булып таудан төшеп килә,
Үргә менеп киткән егетләр…

Яшәр өчен түгел гомер тавы,
Күрер өчен генә биектән.
Томыш юлы җир өстеннән үтә,
Бар яшәеш җиргә береккән.

Ярты юлда туктап калмый гына,
Ярыйда ул әле баралсаң.
Адашмыйча, каты давылында,
Егылмыйча әгәр калалсаң.

Кешедә бит, бары җан иясе,
Җир йөзендә килә яшәсе.
Кычкырасы килә кайвакытта,
«Без кеше бит» диеп дәшәсе…

# Сыналу вакыты…

Бер мәлне үзгәрде барысы,
Яктылык кимеде шикелле…
Бер илдән бер илгә вируслар,
Чикерткә шикелле сикерде.

Даруын табалмый, давалый табиблар,
Югалып калгандай бар халык.
Сугыш юк, ачлык юк шикелле,
Тукталып калгандай бик арып.

Озакка җитәрме бу хәләт…
Без шулай күпмеләр яшәрбез.
Билгесез иртәгә – буласы…
Ярдәмгә Аллаһка дәшәбез.

Ул гына белүче алда ни буласын,
Әфәтнең бетәсе көннәрен…
Самолет- танклар файдасыз,
Шаһидтер белгәнең, күргәнең.

Тынгандай бар дөнья, бөтен җир,
Тукталган шикелле хәрәкәт…
Ни булып бетәсен белмәгәч,
Яшәүдә беткәндәй бәрәкәт.

Бер сынау мизгеле бары тик,
Ә күпме халыкка кагыла.
Кайлардан көтәргә ярдәмне…
Битараф Аллаһның барына.

Вируслар күренми, беленми,
Кешенең йөзендә, кулында.
Галимнәр бер нидә белмәгән,
Бүгенгә ул вирус турында…

Дәлиллек барыбыз өчендә,
Галәмнең хуҗасы бер генә.
Сәбәпче булырмы аңларга,
Җаваплар бирәсе көн генә.

# Онытма язларны

Онытма язларның килүен,
Урамда кояшның көлүен…
Арыныйк күңелсез хисләрдән,
Онытып вируслар йөрүен.

Вируслар китәрләр, бетәрләр,
Бездәге курыкуны көчәйтеп.
Аңларбыз без кайбер әйберне,
Ишетми йөргәнне ничә әйтеп.

Кешенең дөньяда урыны,
Билгеле – язылып куелган…
Күрәсе булганны күрәсең,
Үзгәрми ул синең, уеңнан.

Гарәсәт, давыллар булалар..
Кай вакыт кагыла күпләргә.
Вакытлар аңлата, күрсәтә…
Кем хуҗа галәмдә, күкләрдә.

# Килде вакыт

Кемдер сүгә көндә хөкүмәтне,
Кем гаепле саный дәүләтен…
Үзе һаман кыргыйлана бара,
Каплап тормый хәттә гәүрәтен.

Күренмәгән вирус килеп кинәт,
Андыйларны бераз «юата».
Кая керер урын тапмаганда,
Коры җирен кинәт чылата.

Бәргәләнә бераз кеше күңеле,
Ярдәм белми каян көтәргә.
Билгесезлек юлда олы киртә…
Ничек аны урап үтәргә.

Гадәтләнгән тормыш туктагандай,
Кемгә тыныч кемгә куркыныч…
Уйлаганда, бараз аңлыйсыңда,
Түләнмәгән кебек зур бурыч.

Калган эшкә, инде карлар яуган,
Бүгенгесен кирәк уйларга…
Тормыш көзе ишек каккан чакта,
Өмет итеп йөрмә туйларга.

Бурычларың сине озатмасын,
Олы юлга чыгып киткәндә.
Каршыласын иде матур җәйләр,
Язлар үтеп җирләр кипкәндә.

# Бер хуҗа

Синдә хуҗа, миндә хуҗа кебек…
Хуҗалыклар гына билгесез.
Кайда күреп була алыр микән,
«Син хуҗасы» дигән билгесен.

Хуҗасызмы бөтен якты дөнья,
Каян килеп чыга вируслар.
Адашалар, бүленәләр кинәт,
Гүләйт итеп йөргән туристлар.

Таныш түгел, көтелмәгән сынау,
Безгә бүген ясый сәяхәт.
Җилдә очкан яфраклар кебек,
Байлыклар һәм бөтен сәясәт.

Кемнән безгә ярдәм килә ала,
Түрәләрдән, яки дәүләттән.
Кайсы безгә дөресерәк сөйли,
Сакланырга иде, гайбәттән…

Ике рәхәт бергә килә алмый…
Савап көтмик, гамәл булмаса.
Сусауларны чиләк баса алмас,
Сулы булып алар тормаса.

Җиңел килгән бәхет сизелми шул,
Кадерләрен авыр аңлавы.
Кеше өчен олы кисәтүдер,
Тормышларның җиңел бармавы.

# Җәй

Язлар җитсә, язлар матур кебек,
Алыштырды хәзер жәйләре.
Күңел анын матурлыгын тоя,
Әллә күңел өчен хәйләме.

Җәйләр җитеп, дөнья үзгәрә шул,
Уяналар бөтен чәчкәләр.
Күңелләре җилкенүен сизә,
Күп яшәгән олы яшьтәләр.

Җәй җылысы, тагы өмет бирә,
Булыр кебек алда гомерләр.
Алдагысын бары Ходай белә,
Күрәселәр аны күрерләр.

Картаясы килми, күңел көтә,
Җәйләр килеп тагын киткәнен.
Тагы беркат язмыш, көткәннәргә,
Матур мизгель бүләк иткәнен.

Еллар шулай, алар йөгерәләр,
Ашыкмаган чактакта күңелләр.
Йөрәк кенә ярсыгандай була,

Тибә башлагандай бүгеннән.

Матурлана бара кебек хәзер,
Җәйләр генә түгел, көннәре.
Күрәселәр, күрелмичә калмас,
Күп булсада инде күргәне.

# Озату

Бик ямансу була күңелләрдә,
Якын кеше китсә мәңгегә.
Буйсынабыз язмыш агышына,
Сорау биреп булмый Тәңрегә.

Көтүләрнең файдалары булмый,
Үкенеүләр генә сакланыр.
Онытылмас, ләкин өйрәнелер,
Ялгыз кебек яшәү башланыр…

Искә төшеп, күңел яраланыр,
Әйтә алмый калган сүзләрдән.
Дога укып, әрвах рухына…
Яшьләр чыккан чакта күзләрдәр…

Хәтер бары берләштерә ала,
Яшәп киткән әби-бабалар…
Без яшибез бүген тормыш диеп,
Ә бездән соң, безнең балалар.

Буш сүзләрнең кирәгедә калмый,
Тормыш кабатланмый барыбер.
Хәтер дигән әйбер җуелмасын,

Туганнарның җирдә каны бер.

Буын белән, буын өзелмәсен,
Күпме генә сулар аксада.
Ул бәйләнеш, кеше күңелендә,
Хәтерләрдә бары саклана.

# Сәясәт

Кемнәр сөйми икән сәяхәтне,
Бер тапкырдан күңел тартыла.
Кемнең балалары читтә укый,
Чит илләрне хурлап халыкына.

Капиталист череп бара диеп,
Бездә кемнәр хәзер байлар соң…
Кемнең балалары «типтерәләр»,
Ә байлыклар килгән кайдан соң.

Кайдан килде яңа хужалары,
Халыкныкы дигән милекнең.
Бездә исә халык өченме соң,
Законнарга язган ирекнең…

Кайчан гына куып җитәрбездә.
Кайчан гына узып китәбез…
Алар җүләр, без акыллы диеп,
Үзебездә ышанып бетәбез.

Без булмаган җирдә әйбәт дигән,
Мәкаль мәгәнәсе ялган дип.
Эшләгәннәр каты байый ала,
Бары ялкау ярлы калган дип.

Кемнәр өчен яхшы хезмәт хакы,
Ә кемнәргә яллар кырымда.
Чит илләрдә, кемнәр план кора,
Күчмә милек алу турында…

# АллаХ сүзе

Аллаһ сүзе иманлылар өчен,
Кеше булса гына иманда.
Ярдәм сорап була курыкмыйча,
Иман юлларында булганда.

Кәферлектә, имансызлар икән,
Алар өчен җаза, кисәтү…
Ялгышканнар адашканнар өчен,
Дөрес юлны кирәк күрсәтү.

Кайдан килә җәннәт сорый алу,
Кәферлектә яшәп киткәнгә.
Кабул була мени андый теләк,
Аллаһыны инкар иткәнгә.

Без беләбез Аллаһ кичерүче,
Кайчан гына тәүбә итсәктә.
Тәүбә өчен һаман вакытлар юк,
Гомер көзләренә җитсәктә.

Бер хикмәте кебек язмышларның,
Хакыйкатьне аңлау чоры бар.
Кемнәрнеңдер әйтер сүзе бар,
Җырланмаган әле җыры бар.

Тормыш юлы авыр, озында ул,
Яллар кирәк кайчак күңелгә.
Учак җылыларын тоеп калыйк,
Әйләнгәнче алар күмергә.

# Июнь

Күңелнеңдә була нечкә чагы,
Өзелердә китәр шикелле.
Куып булмый эчтән кайвакытта,
Уйга килгән шикле фикерне.

Биек галәмнәрдә уйлар оча,
Ә сукмаклар үтә җирләрдән.
Аңлый алам алга барумны,
Каршы искән көчле җилләрдән.

Искә төшә икән үткәннәрең…
Димәк юллар эзсез булмаган
Гомер юлы, зарланырлык түгел
Җир йөзендә төссез узмаган.

Яңартасың икән хәтереңне,
Сәфәр кебек күптән үткәнгә.
Шатланулар бирә очрашуда,
Ул мизгельне өзелеп көткәнгә.

Өмет бирә безгә яшәү көче,
Ә хәтердә барсы саклана.
Җылы чагы күбрәк булган икән,

Барысыда истә калсада.

# Сәләм бирик

Чын күңелдән әйткән сәләм сүзе,
Күпме мәгънә эченә җыя ала.
Сәләмәтлек теләп хәлен белү,
Кеше өчен шатлык була ала.

Битарафтан, ихлас сәләм булмас,
Кабул итсәдә ул башкадан.
Очрашулар кеше язмышында,
Сәләм сүзе белән башланган.

Сәләм сүзе, күңел сүзе кебек,
Чын булмаса, җиңел әйтелмәс.
Сәләм сүзе кабул булмый калмас,
Йөрәгеңнән чыгып әйтелгәч.

Синең сәләм, синең догаң кебек,
Кеше белән сәләм алышу.
Ул бит була шулай кешеләрчә,
Тормышларда яшәп барыш ул.

Сәләм биреп яшик якыннарга,
Сәләм сүзен ишетеп торсыннар.
Сәләм алып, сәләмәтлек теләп,
Аллаһыга дога кылсыннар.

# Язмышка

Белеп буламы соң, ишетмәсәң,
Үз күзләрең белән күрмәсәң.
Укыганны, ишеткәннәрңне,
Колагыңа «элә» белмәсәң.

Белем- юллар, безгә үтәр өчен,
Кирәк җиргә барып җитәргә.
Ният белән гамәл шикеллеләр,
Белгәнеңчә кирәк үтәргә.

Бармы файда эшләнмәгән эштән,
Кирәк икәнлеген белептә.
Сәләм бирми узып киткән кебек,
Якын танышыңны күрептә.

Күңелләргә якын булганнары,
Язмыш юлларыңны салада.
Үзең сайлап ала алганнарың,
Эзләр булып җирдә калада.

Язмыш юлы кешедәндә тора,
Кушылганча аны узмасаң.
Биргән язмышыңны саклый алып,

Үз кулларың белән бозмасаң…

# Яңа тормыш

Үзгәрә шул әнә заманалар,
Тамашалар кинәт кимеде.
Экраннарга күчә барысыда,
Әллә хәзер әкият илеме…

Шаяртулар, ямьсезләнеп бетте,
Күтәрелде хакы гайбәтнең.
Язганнарның аермасы юктай,
Ялган белән дөрес әйбәтнең.

Мәзәк ясап, ялгыш егылганнан,
Лайк өчен сатып намусын.
Серен сата мәзәк өчен диеп,
Мыскыл итә якын танышын.

Артист булды хәзер ярты халык,
Бүлешәләр төн һәм таңнарын.
Ни ашаган,ниләр сатып алган,
Кемнәр белән кая барганын.

Колхозчыда, эшчедә юк хәзер,
Сатучыда, сатып алучы.
Калганнары телевизор аша,
Аптырашып карап ятучы.

# Урамда аккош

Аккошлар кайталар, киләләр,
Оялар коралар язларда.
Күлләргә күркәмлек бирәләр,
Пар булып суларда йөзгәндә.

Сокланмый буламы карарга,
Күлләрдә йөзүен аккошның.
Булганмы кайчандыр күргәне,
Урамда йөргәнен аккошның.

Танышу теләге булганмы,
Әллә ул адашып юлыккан…
Кешеләр янына килгән бит,
Урамга менгән бит сулыктан.

Аккошлар матурлык билгесе,
Кошларның олысы, аклары.
Нигәдер урамнан, ялгыз кош,
Тып тыныч курыкмый атлады..

Сирәк хәл тормышта очырый,
Кемнәрнең буладыр күргәне.
Бармы икән, кайсыдыр авылда,
Аккошның урамда йөргәне…

# Сулар ага

Агымсулар үз юлларын таба,
Ә ярлары түбән тын акса.
Сулар агып кына ярлар ясый,
Көчле агым булып ул акса.

Зур елгада биек ярлар була,
Киң урыннар, ярлар арасы…
Күпме сулар ага бу юл аша,
Күпме сулар бардыр агасы.

Тыңлаганда агым тавышларын,
Ул тавышта нинди серләр бар.
Аңлый алсак агым тавышларын
Безгә алар ниләр сөйләрләр…

Елга, чишмә, бөтен су җиһаны,
Аңлап бетермәслек нигъмәт бит.
Сусаганда әдәм баласына,
Тамчысыда нинди кыйммәт бит.

Мохтаҗлыкның файдасыда бардыр,
Булганнарның кадрен белергә.
Эшлибезме, барлык кушылганны,
Чын нигъмәтне җирдә күрергә.

# Туган тел

Туган тел кадере артамы,
Әллә соң бөтенләй югала.
Акырынлап сизелми яшәүдә,
Бөтенләй бетүгә юл ала.

Татарны дуслар бит якламый,
Саклана ул үзен сакласа.
Бирелеп замана шаукына,
Ялгышып үз телен сатмаса.

Кем боза үз телен уйламый,
Тырышып кушабыз дустелен.
Дуслар бит татарча өйрәнми,
Беләләр бары тик үз телен.

Ике дус сөйләшми татарча,
Татарлар тырыша дусларча.
Туган тел күчә ала балага,
Укы дип син дәүләт кушканча.

Кешене кеше иткән теле бар,
Иманлы итүче дине бар.
Шуларны югалтмый яшәрлек,

Халыкның яшәгән җире бар.

# Җирдәгеләр

Җирдә яши алу мөмкинлеге,
Тормыш диеп бездә атала.
Кеше барыбер аңлап бетерә алмый,
Ул юллардан ничек барсада.

Кырган кебек җирдә олы эшләр,
Кеше сизә үзен хуҗадай…
Күпме аның җирдә өлеше бар,
Ул турыда, һичтә уйламай.

Тырышсада үзе оча алмый,
Ул балыктай суда йөзә алмый.
Артык теләк аны бозып куя,
Нәфесенә кеше түзә алмый.

Җирдә нигъмәт иксез-чиксез кебек,
Булдырам дип күпме алсаңда.
Туймас кебек, аңа җитмәс кебек,
Җир йөзендә үзе калсада.

Кеше өчен шундый язмышлардыр,
Бу дөньяда безне сынарга.
Вакыт бармы күпме җирдә яшәп,
Шөкер итеп дога кыларга…

# Хобби

Күп кешенең сөйгән шөгеле була,
Кәсеп түгел, күңел теләге.
Аннан башка яшәү яме җитми,
Булмасада яшәү терәге.

Хобби диләр бугай чит илләрдә,
Безнеңчә ул шөгел, мавыгу.
Бирелеп китеп оныту барысын,
Күңелләргә әйбәт дару ул.

Кем балыкка йөри онытылып,
Кем үстерә матур чәчәкләр.
Кайберәүләр бал кортлары кебек,
Балын эзли һәрбер чәчәктән.

Тәбигатьне кемдер якын итә,
Кемнәр җырлый, кемнәр җыр яза.
Теләкләрең булса күңелеңдә,
Мөмкинлекләр бар бит дөньяда.

Күрә белсәк якын тирә якны,
Күңел күзе булса көчлерәк.
Кабатланмас гомер бирәү генә,

Матур яшәү өчен көч кирәк.

# Бәйрәмме

Күп бәйрәмнәр, берәү санын белми,
Көннәр калмый инде бәйрәмсез.
Чорлар үтә карантинда кебек,
Еллар үткән кебек җәйләрсез.

Нинди бәйрәм була ала икән,
Безгә бармы анда мәгәнә.
Биеп яшәп, яп ят бәйрәмнәрдә,
Үз бәйрәмен белми, тәгәнә…

Бәйрәм бит ул, көтеп алган шатлык,
Ул көннәрдә кәеф сафлана.
Вакыт үтә, бәйрәм ераклаша,
Ә күңелдә озак саклана.

Арзан бәйрәм, буш күңелләр өчен,
Бәйрәм ямен аңлый белмәгән.
Уйлап табып яңа бәйрәмнәрне,
Гомерендә бәйрәм күрмәгән.

Кошлар көне, ак аюлар көне,
Дуслар көне, дошман бәйрәме…
Күңелеңдә үз бәйрәмең бармы,

Шул турыда уйлыйк әйдәле…

# Ниләр истә

Болыннары, чәчү басулары,
Тагын ниләр калган хәтердә.
Күңелләрдә ниләр уелып калып,
Күз алдында тора хәзердә.

Сакланганмы якты кичерешләр,
Оныткannарыда шактыйдыр.
Якты эзләр, әгәр калган булса,
Онытсамда, күңел саклыйдыр.

Китапларны ачып карап була,
Үткән язмыш күпкә катлаулы.
Безгә биргән, тормыш мизгелләрен,
Хәтер дәфтәрендә саклауны.

Язып бару барысын мөмкин түгел,
Истә кала якты юллары…
Уйлар белән ул юлларга кайтып,
Сизә алса күңел кыллары.

Тормыш яме төрле һәркем өчен,
Һәр күңелгә кирәк юаныч.
Үткәннәрне уйлап җылы тойсаң,
Шул буладыр, тормыш куаныч…

# Ифтар

Рамаданда ике шатлык,
Уразада булганда.
Беренчесе Аллаһ өчен,
һәм Ифтарлар булганга.

Ифтарларның мөһимлеге,
Китапларда җавабы.
Ифтарлар үткәрүчегә,
Уразадай савабы.

Уразаның ифтарлары,
Күңелләрне нечкәртә.
Тарвихлар бәйрәм төсле,
Ифтардан соң кичләрдә.

Ифтар әле вәгәздә ул,
Коран уку һәм дога.
Мәрхүм булган кардәшләрне,
Искә алуда була.

Изге айда, изге гамәл,
Савапларга мөмкинлек.
Сафландыру күңелләрне
Җиңел генә мөмкин бит.

# Үзгәреш

Билгесезлек бүген хөкүм сөрә,
Чирләр көтеп чирләп ятабыз.
Өйдән чыгар өчен рөхсәт кирәк,
Кемнәр ничек, гайбәт сатабыз.

Замананың яңа геройлары.
Яңа юллар әллә сызамы.
Акыл сатыр өчен халыкка,
Озын киңәшмәләр узамы.

Авызына карап яши яши,
Хөкүмәттән барсын көтәбез.
Коллык хисен якын итә итә,
Кешелектән чыгып бетәбез.

Башлылар күп, бөтен ил тулы,
Акыл бирүчеләр туктады.
Вакыт үткәч, белгеч күбәер,
Ә хәзергә бердә юк әле.

Алдан белүчеләр эндәшмиләр,
Шарлатаннар нидер уйлана.
Йокы түгел, җиһан үзгәрә,
Төшләр генә диеп уйлама.

Тыныч үткән олы давыл кебек,
Җир өстендә тормыш үзгәрә.
Сәбәпләре әле ачыкланыр,
Барып җитәр әле безгәдә.

# Бүген

Дөньялар киң, юллар такыр,
Бүген тормыш шулай бармыш.
Харам белән хәләл бергә,
Кичә айнык, бүген салмыш.

Телдә иман, күңелләр буш,
Ниятләр бар гамәлләр юк…
Җиткән кебек барысыда,
Өсләр бөтен, тамаклар тук.

Элеккеләр онытыла…
Яңаларны таба алмыйбыз.
Урында да тора алмыйбыз,
Алгада без бара алмыйбыз.

Салкын хәзер карашларда,
Елмайганнар, җүләр кебек.
Бүген халык дөнья диеп,
Батырларча үләр кебек.

Ят бәйрәмнәр гөрләп үтә,
Яңа диеп тырышабыз.
Үзебезнең эшләр мөшкель.

Башкаларга булышабыз.

Гөнаһ җыеп узышабыз,
Нәфес безне, каты җигә.
Канәгатьлек каян килә,
Рәхәт табып кайсы җиргә…

Кемнәр безне уятыр соң,
Йоклаганнар булмасакта.
Бозыклыклар арасында,
Бозык булып тумасакта.

Күңелләргәниләр булды,
Ниләр анда кереп тулды…
Аңладыкта, соңардык шул,
Бушатырга бик соң булды.

# Ике күпер

Елга тирән булмаса да,
Авылыбызда ике күпер.
Бәләкәй һәм олы күпер,
Икеседә төзек, бөтен.

Гелдә алай булмаганнар,
Су агызгач ясаганнар.
Олы күпер аша җәяү,
Урау юл дип атаганнар

Олы күпер элегерәк,
Бик олыда була алмаган.
Комбайннар һәм чәчкечләр,
Аның аша чыга алмаган.

Запас чара – елга аша,
Иплэп кенә кереп чыгу.
Ялгышырак кыланганда,
Су читендә кереп «чуму».

Яшәү өчен авыр вакыт,
Заманасы шундый булган.
Кул астында ни табылса,
Кеше шуннан күпер корган.

Таш, тимердән хәзер алар,

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.